# Песикәем

1. Мәче баласы бар минем
   Йоклаганда мырылдый,
   Шуңа күрә аны яратамын
   Ул бит миңа җыр җырлый

Кушымта: Песи-песи пескәем
Әйдә утыр яныма
Синең белән уйнасам
Рәхәт була җаным

2. Мәче баласы бар минем
   Сәгать саен юына
   Мин сокланым карап торам
   Аның уңганлыгына

Кушымта: Песи-песи пескәем
Эй озындыр мыегың
Нинди матур һәм йомшак
Ак мамыктай койрыгың

3. Мәче баласы бар минем
   Күзгә карап утыра
   Китап ачсам сырпалана
   Өйрәт диеп утыра

Кушымта: Песи-песи пескәем
Синең кебек үземдә
Укый белмим әле мин
Әни дигән сүзне дә